| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1081

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районының һәм шәһәр округының җирле үзидарә органында, оешмаларда эшләүче һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә карата бертип таләпләр стандартын һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 2 октябрь, 894 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районының һәм шәһәр округының җирле үзидарә органында, оешмаларда эшләүче һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә карата бертип таләпләр стандартын һәм Татарстан Респуб-ликасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 2 октябрь, 894 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органында, Татарстан Республикасы муниципаль районы һәм шәһәр округы җирле үзидарә органында, оешмаларда эшләүче һәм Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә карата бертип таләпләр стандартында:

1 бүлекнең 1.1 нче пунктында «билгеләүне аныклый һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектә:

2.1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.1. Бүленгән үзәккә керүче һәр ситуацион үзәк өчен ситуацион үзәк паспорты эшләнә һәм теркәлә. Паспорт ситуацион үзәк төзелә һәм эшли торган оешма (алга таба – гариза бирүче) тарафыннан тутырыла. Паспорт ситуацион үзәкнең составын, торышын һәм аннан файдалану шартларын чагылдыра. Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләр реестрында (алга таба – Ситуацион үзәкләр реестры) код алу һәм алга таба исәбен алып бару өчен гариза бирүче тарафыннан паспорт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Бүленгән үзәктә катнашучылар эшчәнлеген яраштыруга җавап бирүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының структур бүлекчәсенә (алга таба – Яраштыручы) тапшырыла. Ситуацион үзәк паспортын тутыру формасы һәм тәртибе бу Стандартка теркәлгән 1 нче кушымтада китерелә.»;

2.2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Бүленгән үзәккә керүче ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү – ул оештыру-техник чаралар комплексы дигәнне аңлата, аның нәтиҗәсендә ситуацион үзәкнең бу Стандарт таләпләренә туры килүе раслана. Моннан тыш, аккредитацияләү кулланыла торган аппарат-техник чараларның, программа платформаларының, файдалану мөмкинлеге дәрәҗәсенең таләп ителә торган дәрәҗәгә туры килүен бәяләү максаты белән ситуацион үзәккә эксплуатацияләүнең реаль шартларында тест ясауны күздә тота.»;

Стандартка теркәлгән 2 нче кушымтаның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләр реестрыннан алынган бу өземтә ________________________________________________________________

(Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) җирле үзидарә органы, оешма исеме, адресы, ИНН)

караган _______________________________________________________________

(ситуацион үзәк исеме)

________________________ ситуацион үзәге Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләр реестрына кертелгән булуын раслый, бу турыда 20__ елның _______________ ______ номерлы язу белән белдерелә.»;

Стандартка теркәлгән 3 нче кушымтада:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Ситуацион үзәк оештырырга.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ситуацион үзәк турындагы нигезләмәне (теркәлә) расларга.»;

8 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«кулланыла торган мәгълүмат системаларын Татарстан Республикасының Мәгълүмат системалары реестрына кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына заявка җибәрергә.»;

«Җитәкче» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитәкче ______________________________________»;
(вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис., имзасы, датасы)

Ситуацион үзәк оештыру турындагы боерыкка теркәлгән «Ситуацион үзәк турында нигезләмә» кушымтасында:

1 бүлектә:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә ситуацион үзәкнең бурычларын, функцияләрен һәм эш тәртибен билгели.»;

1.2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәгълүмат ресурсы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм хуҗалык итүче субъектларның Татарстан Республикасы Бүленгән ситуацион үзәгенең мәгълүмат системалары составына керә торган мәгълүматы;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ситуацион үзәк администраторы – ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итә торган вәкаләтле бүлекчә;»;

тугызынчы абзацта «бүлекләр» сүзен «бүлекчәләр» сүзенә алыштырырга;

3 бүлектә:

3.1 нче пунктның икенче абзацында «бүлекләрнең» сүзен «бүлекчәләрнең» сүзенә алыштырырга;

3.2 нче пунктның беренче абзацында «бүлекләр» сүзен «бүлекчәләр» сүзенә алыштырырга;

4 бүлектә:

4.4 нче пунктта «бүлек белән» сүзләрен «мәгълүмат технологияләрен үстерү өчен җаваплы бүлекчә белән» сүзләренә алыштырырга;

Стандартка теркәлгән 4 нче кушымтада 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Ситуацион үзәк эшчәнлеге турындагы хисаплылык формасын (теркәлә) расларга.»;

Стандартка теркәлгән 5 нче кушымтаның 2.1 нче пунктында «министрлык/ведомство исеме» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Бүленгән ситуацион үзәгенә керүче ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турындагы нигезләмәдә:

3 бүлектә:

3.2 нче пунктта:

икенче абзацта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзацка «(кирәк булганда)» сүзләрен өстәргә;

3.3 нче пунктның икенче абзацында «система эшчәнлеге» сүзләрен «тәртибен һәм процедурасын» сүзләренә алыштырырга;

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Аккредитацияләүгә заявка бирү ситуацион үзәкне Татарстан Республикасының ситуацион үзәкләр реестрына теркәгән көннән бер ай эчендә тиешле ситуацион үзәкне аккредитацияләү өчен гариза бирүче тарафыннан аккредитацияләүче структур бүлекчә адресына ситуацион үзәк оештыру һәм аның эшчәнлеген җайга сала торган документлар теркәлгән рәсми сорау җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Аккредитацияләүгә заявканы карап тикшерү өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

4.5 нче пунктта:

җиденче абзацта «шулай ук ситуацион үзәк эшчәнлеген тикшерүдә тоту буенча тәкъдимнәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

тугызынчы абзацта «экспертлар тарафыннан» һәм «сынауларны үткәрүчеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада 4 нче пунктны төшереп калдырырга;

Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада 6, 6.1, 6.2 нче пунктларны төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин